**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об образовании Инвестиционного совета Республики Татарстан» и признании утратившими силу отдельных указов Президента Республики Татарстан

В целях совершенствования деятельности Инвестиционного совета Республики Татарстан **постановляю:**

1. Упразднить Совет при Президенте Республики Татарстан по взаимодействию с международными финансовыми организациями, возложив осуществление его функций на Инвестиционный совет Республики Татарстан.

2. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 5 июля 2012 года № УП-538 «Об образовании Инвестиционного совета Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 6 сентября 2012 года № УП-745, от 3 ноября 2012 года № УП-914, от 20 марта 2013 года № УП-242, от 29 марта 2013 года № УП-258, от 8 августа 2013 года № УП-717, от 29 апреля 2014 года № УП-440, от 27 августа 2014 года № УП-826, от 2 марта 2015 года № УП-199 и от 13 октября 2015 года № УП-984) следующие изменения:

а) в Положении об Инвестиционном совете Республики Татарстан:

раздел 2 изложить в следующей редакции:

«**2. Основные задачи и функции Инвестиционного совета**

Основными задачами и функциями Инвестиционного совета являются:

рассмотрение и анализ инвестиционных проектов на предмет целесообразности их реализации на территории Республики Татарстан и необходимости (возможности) их софинансирования за счет средств бюджета Республики Татарстан, местных бюджетов;

определение основных направлений развития государственно-частного партнерства и решение иных задач, направленных на совершенствование механизмов государственно-частного партнерства в Республике Татарстан;

рассмотрение вопросов взаимодействия исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан с международными финансовыми организациями в целях привлечения финансовых и

экономических ресурсов международных финансовых организаций для реализации инвестиционных проектов и программ, направленных на социальное и экономическое развитие Республики Татарстан;

рассмотрение предложений органов государственной власти Республики Татарстан по реализации инвестиционных проектов на территории Республики Татарстан с участием международных финансовых организаций, а также предложений международных финансовых организаций по оказанию финансового и технического содействия Республике Татарстан;

разработка предложений по:

- размещению на территории Республики Татарстан объектов в рамках реализации инвестиционных проектов и программ;

- организации взаимодействия исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан и лиц, участвующих в инвестиционном процессе;

- уменьшению административных барьеров, в том числе в части сокращения сроков и упрощения процедуры выдачи разрешительной документации;

- приоритетным направлениям развития Республики Татарстан и координации финансовых и инвестиционных ресурсов на наиболее важных направлениях;

- государственной поддержке инвестиционных процессов и стимулированию инвестиционной активности на территории Республики Татарстан;

- установлению единых требований к основным критериям инвестиционных проектов, поддерживаемых за счет средств федерального бюджета и бюджета Республики Татарстан;

рассмотрение результатов реализации инвестиционных проектов;

рассмотрение регулярных отчетов органа, уполномоченного на проведение оценки регулирующего воздействия.»;

в пункте 4.4:

абзац третий изложить в следующей редакции:

«разработку предложений по размещению на территории Республики Татарстан объектов в рамках реализации инвестиционных проектов и программ;»;

дополнить абзацем пятым следующего содержания:

«рассмотрение вопросов, связанных с предоставлением инвесторам земельных участков в соответствии с земельным законодательством;»;

абзацы пятый и шестой считать соответственно абзацами шестым и седьмым;

б) в составе Инвестиционного совета Республики Татарстан (далее – Совет):

вывести из состава Совета Р.Х. Зарипова, Р.Х. Миннегалиева;

ввести в состав Совета:

Бурганова Рафиса Тимерхановича – председателя Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по экономике, инвестициям и предпринимательству (по согласованию);

Гараева Зуфара Фаниловича – председателя правления Акционерного коммерческого банка «АК БАРС» (публичное акционерное общество) (по согласованию);

Даутову Евгению Валентиновну – председателя правления Акционерного коммерческого Банка «Спурт» (публичное акционерное общество) (по согласованию);

Кузнецова Артема Александровича – начальника Управления Федеральной миграционной службы по Республике Татарстан (по согласованию);

Сафиуллина Марата Адиповича – руководителя Управления Федеральной налоговой службы по Республике Татарстан (по согласованию);

Якунина Леонида Александровича – председателя Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по бюджету, налогам и финансам (по согласованию);

изложить в следующей редакции наименования должностей членов Совета:

А.А. Каримова – «заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр промышленности и торговли Республики Татарстан»;

А.П. Лаврентьева – «президент Ассоциации предприятий и промышленников Республики Татарстан (региональное объединение работодателей) (по согласованию)»;

А.М. Пахомова – «генеральный директор Ассоциации предприятий и промышленников Республики Татарстан (региональное объединение работодателей) (по согласованию)»;

Р.С. Ханбикова – «генеральный директор акционерного общества «Газпром межрегионгаз Казань» (по согласованию)».

3. Признать утратившими силу:

Указ Президента Республики Татарстан от 14 октября 2010 года № УП-696 «Об образовании Совета при Президенте Республики Татарстан по взаимодействию с международными финансовыми организациями»;

Указ Президента Республики Татарстан от 5 марта 2011 года № УП-110 «О внесении изменений в состав Совета при Президенте Республики Татарстан по взаимодействию с международными финансовыми организациями»;

Указ Президента Республики Татарстан от 23 марта 2011 года № УП-145 «О внесении изменений в состав Совета при Президенте Республики Татарстан по взаимодействию с международными финансовыми организациями»;

пункт 3 Указа Президента Республики Татарстан от 6 сентября 2012 года № УП-745 «О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан».

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
29 июня 2016 года
№ УП-553

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция советын төзү турында» Указына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указлары үз көчен югалтуын тану хакында**

Татарстан Республикасы Инвестиция советы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президенты каршында халыкара финанс оешмалары белән үзара хезмәттәшлек советын, аның функцияләрен тормышка ашыруны Татарстан Республикасы Инвестиция советына йөкләп, бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция советын төзү турында» 2012 елның 5 июлендәге ПУ-538 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-745 номерлы, 2012 елның 3 ноябрендәге ПУ-914 номерлы, 2013 елның 20 мартындагы ПУ-242 номерлы, 2013 елның 29 мартындагы ПУ-258 номерлы, 2013 елның 8 августындагы ПУ-717 номерлы, 2014 елның 29 апрелендәге ПУ-440 номерлы, 2014 елның 27 августындагы ПУ-826 номерлы, 2015 елның 2 мартындагы ПУ-199 номерлы һәм 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-984 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Инвестиция советы турында нигезләмәдә:

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**2. Инвестиция советының төп бурычлары һәм функцияләре**

Инвестиция советының төп бурычлары һәм функцияләре түбәндәгеләр:

инвестиция проектларын Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгы һәм аларны Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар акчалары хисабына бергәләп финанслау кирәклегенә (мөмкинлегенә) кагылышлы карау һәм анализлау;

дәүләт-хосусый партнерлыгын үстерүнең төп юнәлешләрен билгеләү һәм Татарстан Республикасында дәүләт-хосусый партнерлыгы механизмнарын камилләштерүгә юнәлтелгән башка бурычларны хәл итү;

Татарстан Республикасының социаль һәм икътисадый үсешенә юнәлтелгән инвестиция проектларын һәм программаларын гамәлгә ашыруга

халыкара финанс оешмалары финанс һәм икътисадый ресурсларын җәлеп итү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының халыкара финанс оешмалары белән хезмәттәшлеге мәсьәләләрен карау;

Татарстан Республикасы территориясендә халыкара финанс оешмалары катнашында инвестиция проектларын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тәкъдимнәрен карау, шулай ук Татарстан Республикасына финанс һәм техник ярдәм күрсәтү буенча халыкара финанс оешмалары тәкъдимнәрен карау;

түбәндәгеләр буенча тәкъдимнәр эшләү:

– Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектлары һәм программаларын гамәлгә ашыру кысаларында объектлар урнаштыру;

– Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм инвестиция процессында катнашучы затларның үзара хезмәттәшлеген оештыру;

– административ киртәләрне киметү, шул исәптән рөхсәт документациясен бирү вакытын кыскарту һәм аларны бирү процедурасын гадиләштерү өлешендә;

– Татарстан Республикасы үсешенең өстенлекле юнәлешләре, финанс һәм инвестиция ресурсларын мөһимрәк юнәлешләрдә координацияләү;

– Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция процессларына дәүләт ярдәме күрсәтү һәм инвестицион активлыкны стимуллаштыру;

– федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан ярдәм күрсәтелә торган инвестиция проектларының төп критерийларына бердәй таләпләр билгеләү;

инвестиция проектларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен карау;

җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыруга вәкаләтле органның даими хисапларын карау.»;

4.4 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектлары һәм программаларын гамәлгә ашыру кысаларында объектлар урнаштыру буенча тәкъдимнәр эшләү;»;

түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

«җир турында законнар нигезендә инвесторларга җир кишәрлекләре бирү белән бәйле мәсьәләләрне карау;»;

бишенче һәм алтынчы абзацларны тиешенчә алтынчы һәм җиденче абзацлар дип санарга;

б) Татарстан Республикасы Инвестиция советы (алга таба – Совет) составында:

Совет составыннан Р.Х. Зариповны, Р.Х. Миңнегалиевны чыгарырга;

Совет составына кертергә:

Борһанов Рафис Тимерхан улын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисен (килешү буенча);

Гәрәев Зөфәр Фәнил улын – «АК БАРС» акционер коммерциячел банкы (гавами акционер җәмгыяте) идарәсе рәисен (килешү буенча);

Даутова Евгения Валентиновнаны – «Спурт» акционер коммерциячел банкы (гавами акционер җәмгыяте) идарәсе рәисен (килешү буенча);

Кузнецов Артем Александровичны – Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Сафиуллин Марат Әдип улын – Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесен (килешү буенча);

Якунин Леонид Александровичны – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты рәисен (килешү буенча);

Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.Ә. Кәримовның – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры»;

А.П. Лаврентьевның – «Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (төбәк эш бирүчеләр берләшмәсе) президенты (килешү буенча)»;

А.М. Пахомовның – «Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (төбәк эш бирүчеләр берләшмәсе) генераль директоры (килешү буенча)»;

Р.С. Ханбиковның – «Газпром төбәкарагаз Казан» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)».

3. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршында халыкара финанс оешмалары белән үзара хезмәттәшлек советы төзү турында» 2010 елның 14 октябрендәге ПУ-696 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Халыкара финанс оешмалары белән үзара хезмәттәшлек советы составына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 5 мартындагы ПУ-110 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Халыкара финанс оешмалары белән үзара хезмәттәшлек советы составына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 23 мартындагы ПУ-145 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-745 номерлы Указының 3 пункты.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 29 июнь
№ ПУ-553